**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«17» гыйнвар 2020 ел** **№28**

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Чубар-Абдул авыл җирлегенең
Генераль план проекты буенча
ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районы Чубар Абдул авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны үткәрү инициаторы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башлыгы.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты: 2020 елның 24 гыйнварыннан 2020 елның 25 февраленә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

үткәрү урыны: Азнакай районы, Чубар Абдул авылы, Совет урамы, 81 нче йорт;

- 2020 елның 25 февраленә кадәр фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Азнакай шәһәре, М.Солтангалиев ур., 24 йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге; Азнакай районы, Чубар Абдул авылы, Совет ур., 81 йорт, Азнакай муниципаль районы Чубар Абдул авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районы Чубар- Абдул авыл җирлеге башкарма комитетына:

-Азнакай муниципаль районы Чубар Абдул авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча, гамәлдәге законнар һәм әлеге карар белән билгеләнгән сроклар буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Азнакай муниципаль районы Чубар Абдул авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышу буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын раслау.

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай

муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http: //aznakayevo.tatar.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М. З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы
башлыгы карарына кушымта
«___» _______ 2020 №_____

Азнакай муниципаль районы Чубар Абдул авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышу турында
ачык тыңлаулар нәтиҗәләре нигезендә бәяләмә әзерләүче турында эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А. Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Әюпова Р. Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Шәрәфетдинова С. Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Фәтхетдинов Н.Ә. | Азнакай муниципаль районы Чубар Абдул авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Н.Г. | Азнакай район Советының җирлекләр белән эшләү секторы мөдире |